КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 декабрь г.Казань № 1344

2022 елда Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасны саклау турында конвенциянең 50 еллыгына Халыкара форумны әзерләү һәм уздыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлардан файдалану кагыйдәләре һәм 2022 елда Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасны саклау турында конвенциянең 50 еллыгына Халыкара форумны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм 2022 елда Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасны саклау турында конвенциянең 50 еллыгына Халыкара форумны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2022 елда Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасны саклау турында конвенциянең 50 еллыгына Халыкара форумны әзерләү һәм уздыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлардан файдалану кагыйдәләре;

2022 елда Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасны саклау турында конвенциянең 50 еллыгына Халыкара форумны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин